# Новости из жизнедеятельности администрации губернатора Самарской области

## Губернатор каршында ветераннарның киңәшмә Шурасы оештырылды

Бу совет губернатор Николай Меркушкин тәкъдиме белән оештырылды. Ветераннар советының төп максаты - өлкәнең социаль-икътисади тормышында ветераннарның хезмәт уңышларын куллану.

Ветераннар советын губернатор Николай Меркушкин җитәкләячәк. Ветераннар советына Самар өлкәсенең төрле тармакта төрле елларда хезмәт иткән күренекле шәхесләре сайланды.

Алар түбәндәгеләр:
Мария Андреева,
Евгений Бойко,
Петр Горшков,
Владимир Золотарев,
Евгений Лаврентьев,
В.И. Ленин исемендәге Куйбышев Металлургия заводында 1989 елдан алып 1996 елга кадәр генераль директор булып эшләгән Максим Оводенко,
1994 елдан алып 2001 елга кадәр Идел буе хәрби округы командующие, генерал-полковник Анатолий Сергеев,
академик Сергей Королев исемендәге Самар дәүләт аэрокосмик университеты җитәкчесе Виктор Сойфер һәм башкалар.

**Шамил БАҺАУТДИН.**

## Самар өлкәсенең үзенчәлеге

Май ае ахырында Самарда бик тә тантаналы шартларда әзәри мәдәниятенә багышланган чаралар уздырылды. Самар губернаторы Николай Меркушкинның бу чарада катнашуы моңа бер дәлил булып тора. Һәр бәйрәмнең "кадагы" була. Әзәрбайҗаннарның Самар филармониясе бинасында узган йомгаклау концерты шундыйлардан булды.

Тантана Әзәрбайҗан республикасының 95 еллыгына һәм "Лига азербайджанцев" җәмгыятенә 10 ел тулуга багышланган иде. Бу ике дата уңае белән губернатор Николай Меркушкин залдагыларны бик җылы котлады һәм Самар өлкәсендә милләтләрнең яхшы һәм тату яшәүләренә килечәктә дә зур игътибар бирәчәкбез, диде.

"Җәмгыятьтә тынычлыктан һәм халыклар дуслыгыннан зуррак байлык юк. Бүгенге тантана нәкъ менә шуңа, халыклар дуслыгы ныгытуга багышлана. Бүгенге бәйрәм әзәриләр өчен генә түгел, Самар өлкәсендә яшәүче барлык милләтләр өчен дә. Һәр кешенең хөрмәтле һәм тиң булып яшисе килә. Дөнья шуңа көйләнгән һәм җайланган", - диде Самар губернаторы Николай Меркушкин.

Губернатор әзәри җәмгыятенең әйдаманнарына төбәктә милләтара мөнәсәбәтләрдә тынычлык вә дуслык урнаштыруда көч куйган өчен мактаунамәләр һәм бүләкләр тапшырды.

"Иң мөһиме шунда ки, Самар төбәгендә 150 милләт тату яши", - диде Николай Меркушкин. Һәм өстәде: бу тынычлыкта әзәрбайҗан милли оешмаларының да өлеше бар.

**Шамил БАҺАУТДИН.**

## «Ел һөнәрмәнде» («Профессионал года») бәйгесе

Самарда бик зурлап төрле һөнәр ияләре арасында бәйге үтте. Самар төбәгендә мондый чара әле беренче мәртәбә генә уздырылды. Төбәк икътисадының барлык тармакларында да бәйгегә зур тырышлык күрсәтеп катнашучыларны барладылар. Конкурс нәтиҗәсе буларак үз хезмәтләренең 57 остасы сайлап алынды.

Бүләкләнүчеләр арасында Иске Ярмәк авылында уңышлы эшләп килүче"Ак каен" исемле татар халык фольклор ансамбленең җитәкчесе Наил Галимуллин да бар иде. Ул "Үзешчән сәнгать коллективының иң яхшы җитәкчесе" исемле номинациядә җиңүче, дип табылды.

Самар губернаторы Николай Меркушкин мондый бәйгеләр ел саен уздырылачак, дип белдерде.

Төбәк җитәкчесе әйтүенчә, эшче кешенең дәрәҗәсен үстерү юнәлешендә, төбәк биеклегендә генә түгел, федераль биеклектә дә эш алып барыла.

Самар өлкәсендә "Трудовая слава" («Хезмәт даны») исемле мактаулы билге кертеләчәк.

"Дәүләт биеклегендә һөнәри кадрларны әзерләү җайга салыначак. Училище һәм колледжлар өчен өр-яңа җиһазлар сатып алыначак. Яшьләр заманча җиһазларда эшкә өйрәнәчәкләр", - диде губернатор Николай Меркушкин.

"Конкуренция чорында һәр һөнәр иясеннән җаваплылык таләп ителә. Һөнәрең буенча син финансистмы, слесарьмы - ул мөһим түгел. Без барчабыз да бер көймәдә. Тик тырыш хезмәтебез генә төбәктә, илдә яшәр өчен уңай шартлар тудырачак. Май бәйрәмнәре халыкны берләштерә иде һәм бу гадәтне яңадан торгызырга кирәк", - диде губернатор Меркушкин.

Төбәк башлыгы иң оста шоферларга, слесарьларга, токарьларга, укытучыларга, шәфкать туташларына һәм башка һөнәр ияләренә дипломнар тапшырды.

Губернатор мондый очрашуларның даими төс алачагын кисәтте.

Җавап сүзе белән Наил Галимуллин чыгыш ясады. Ул мәдәният хезмәткәрләренә игътибар артуга куанычын белдерде."Эш хакыбыз түбән булу аркасында, без моңа кадәр икешәр җирдә эшләргә мәҗбүр идек. Хәзер инде бер җирдә генә җиң сызганып эшләү мөмкинлеге туды", - диде "Ак каен" ансамбле җитәкчесе Наил Галимуллин.

**Шамил БАҺАУТДИН.**



**Самар өлкә Сабан туенда өлкә администрациясе вәкиле Дмитрий Овчинников журналистларның күп сорауларына җавап бирде**



**25нче өлкә Сабан туенда губернатор Николай Меркушкин исеменнән халыкны бәйрәм белән аның урынбасары Дмитрий Овчинников котлады. Самар өлкә татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Минәхмәт Хәлиуллов шәрәфле кунакка түбәтәй һәм чапан бүләк итте**

## Губернатор встретился с журналистами

6 июня в Самаре в здании областного правительства прошла пресс-конференция губернатора Николая Меркушкина. «Последний раз мы с вами встречались в октябре прошлого года. Сегодня у нас более представительный состав средств массовой информации, только блоггеров аккредитовалось 40 человек», — обратился к присутствующим глава региона.

Вопрос, заданный главным редактором газеты «Волжская коммуна» Александром Комраковым, касался итогов годовой работы регионального правительства в новом составе.

«Прогресс есть, но некоторые вопросы решаются долго», - заявил губернатор. Николай Меркушкин ответил на вопрос о сроках выплат на жилье молодым семьям. «Это федеральная программа, в которой мы участвуем и выделяем софинансирование. Самарская область сейчас на первом месте в стране по размеру субсидий, выделяемых из федерального бюджета», — ответил глава региона.

Губернатору был задан вопрос о досрочных выборах мэра Самары. «Я не вижу никакой необходимости переизбирать мэра областного центра», - заявил глава области.

Николай Меркушкин ответил на вопрос о главной цели своей жизни.«Сегодня главная цель моей жизни — сделать все, чтобы самарцам и региону приносить пользу», — заявил губернатор. В ходе пресс-конференции губернатора Самарской области Николая Меркушкина была поднята тема взаимоотношений власти и бизнеса. «Вы не раз говорили, что самарский бизнес не работает на благо губернии. Нашли ли точки соприкосновения?» — прозвучал вопрос. «Я никак не ожидал, что если, например, мы срочно не выделим ПФК «Крылья Советов» 45 млн рублей, то их снимут с чемпионата. В Мордовии, например, так вопросы не ставятся. Есть люди, бизнесмены, которые занимаются командой. Для них это имиджевые вопросы, и они знают, зачем оказывают поддержку команде. А в Самаре этого нет», — заметил губернатор.

Инициатива изменения схемы выборов в ряде муниципальных образований Самарской области исходила не от Николая Меркушкина. Об этом сам губернатор рассказал во время пресс-конференции. Николай Меркушкин заявил, что в ряде муниципальных образований исполнительная власть долгие годы не занималась ее непосредственными обязанностями — благоустройство, ЖКХ, дороги. Глава области сообщил, что для реализации масштабных сельскохозяйственных проектов требуется высокий уровень технологий и высококвалифицированный менеджмент.

Губернатор Самарской области Николай Меркушкин на пресс-конференции ответил на вопрос о состоянии самарских дорог. Глава региона напомнил, что в этом году областной центр получил беспрецедентные суммы на ремонт дорог, однако за соблюдением их качества и соответствием сметных расходов реальным установлен особый контроль.

Губернатору было задано очень много самых разных вопросов, на которые он отвечал обстоятельно и подробно.

***Али СУЛЕЙМАНОВ.***